СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча райзон Советы**
**КАРАРЫ**

**«_28_ »_февраль_ 2022 ел** **№ _118_**

**Арча район Советы аппаратының кадрлар секторы турында нигезләмәне раслау хакында**

Арча муниципаль районының вәкиллекле органы аппараты структурасы үзгәрүгә бәйле рәвештә, Арча район Советының 28.02.2022 ел, №116 карары нигезендә Арча район Советы карар бирде:

1.Арча район Советы аппаратының кадрлар секторы турында нигезләмәне (алга таба-Нигезләмә) кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 10 мартыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
28 февраль 2022 ел, № 118
карары белән
**РАСЛАНДЫ**

## Арча район Советы аппаратының кадрлар секторы турында
## НИГЕЗЛӘМӘ

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Арча район Советы (алга таба - Совет) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советы эшчәнлеген кадрлар белән тәэмин итү өчен, шулай ук кадрлар сәясәтен һәм муниципаль хезмәтне оештыру функцияләрен гамәлгә ашыру өчен үз составында кадрлар секторы төзи.

1.2. Арча район Советы аппаратының кадрлар секторы (алга таба - Сектор) Арча район Советы аппаратының структур бүлекчәсе булып тора.

1.3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Советының һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетының, башка җирле үзидарә органнарының, шулай ук Арча муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең үзара хезмәттәшлеге турында килешүләр нигезендә Сектор Арча район Советында кадрлар сәясәтен һәм муниципаль хезмәтне оештыру функциясен башкара.

1.4. Сектор юридик зат статусыннан башка төзелә, Сектор алдына куелган бурычларны хәл итү өчен, билгеләнгән тәртиптә Арча район Советы һәм Башкарма комитетының мөһере һәм штампларыннан файдалана.

1.5. Сектор үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе,Россия Федерациясе Президенты Указлары, Федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы Президенты Указлары, Татарстан Республикасы законнары, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль закон, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Арча муниципаль районы Уставы, Арча муниципаль районы Советы карарлары, Арча муниципаль районы башлыгы карарлары һәм күрсәтмәләре, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары һәм күрсәтмәләре, Башкарма комитет турында Нигезләмә, Арча район Советының, Башкарма комитетның эш регламенты һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.6. Сектор штаты Арча район Советы аппаратының штат расписаниесе нигезендә туплана.

1.7. Сектор муниципаль район территориясендә үз эшчәнлеген Арча район Советының һәм муниципаль район башкарма комитетының башка структур бүлекчәләре, вәкиллекле хакимияте органнары, җирле үзидарә

органнары, оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр белән берлектә гамәлгә ашыра.

1.6. Бүлек эшчәнлеген Арча район Советы аппараты җитәкчесе тикшереп тора.

## 2. Секторның бурычлары

Үзенең төп функцияләре нигезендә Сектор түбәндәге бурычларны хәл итә:

2.1. Муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәткә керүенә, муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнүенә, аны узуга, муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителүенә, муниципаль хезмәттән китүенә, аның пенсиягә чыгуына һәм шулай ук коррупциягә каршы тору мәсьәләләренә бәйле муниципаль хокукый актлар проектларын, башка документлар әзерли;

2.2. Муниципаль хокукый актлар Секторга йөкләнгән функцияләр нигезендә законнар яисә югары юридик көчкә ия муниципаль хокукый актлар нормаларына каршы килгән очракта, муниципаль хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында яки муниципаль хокукый актларны гамәлдән чыгару (үз көчен югалткан дип тану) турында тәкъдимнәр әзерли;

2.3. Кадрлар әзерләүнең һәм аларның квалификациясен күтәрүнең барлык төрләрен оештыра һәм уздыра;

2.4. Кадрларны исәпкә алу, муниципаль хезмәткәрләрне һәм хезмәткәрләрне эштән чыгаруны оештыра, хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштерә;

2.5 Арча район Советы һәм Арча муниципаль районы Башкарма комитеты хезмәткәрләренең еллык һәм өстәмә отпусклар графигы нигезендә еллык һәм өстәмә отпусклар бирүне тәэмин итә;

2.6. Арча район Советы һәм Башкарма комитет эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәткәрләргә һәм хезмәткәрләргә хезмәт хакына айлык өстәмә түләүләр һәм матди кызыксындыру билгеләү (үзгәртү) буенча күрсәтмә документлар әзерли;

2.7. Арча район Советы һәм Башкарма комитеты хезмәткәрләренең, муниципаль унитар предприятиеләр һәм муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең шәхси эшләрен һәм шәхси карточкаларын алып бара;

2.8. Арча район Советы һәм Башкарма комитеты хезмәткәрләренә билгеләнгән тәртиптә хезмәт таныклыкларын рәсмиләштерә һәм бирә;

2.9.Билгеләнгән формалар буенча хәрби бурычлылыкны исәпкә алуны һәм хисаплылыкны алып бара;

2.10. Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләренә тиешле еллар эшләгән өчен дәүләт пенсиясен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәттәшлек итә;

2.11. Муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләрен әзерләүдә һәм килештерүдә катнаша;

2.12. Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре реестрын, Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрын алып бара;

2.13. Муниципаль хезмәт вазыйфаларына карамаган һәм Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеген техник яктан тәэмин итүче вазыйфалар исемлекләрен алып бара һәм аларга үзгәрешләр кертә;

2.15. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» дәүләт мәгълүмат системасында эш оештыра;

2.16. Кадрлар резервы белән эшләүне һәм аннан нәтиҗәле файдалануны оештыра;

2.17. Муниципаль хезмәткәрләргә ташламалар һәм гарантияләр бирү өчен муниципаль хезмәт стажын исәпләп чыгара;

2.18. Аттестация комиссиясе, муниципаль хезмәт стажын билгеләү комиссиясе, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итә;

2.19. Арча муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренә квалификация имтиханын әзерләү һәм үткәрүне тәэмин итә;

2.20. Муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар уздыруны тәэмин итә;

2.21. Муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәүләрен, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне үтәүләрен тикшереп тора;

2.22. Нинди дә булса затларның аларны коррупцион хокук бозуларны кылуга этәрү максатыннан яллаучының вәкиленә, Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына мөрәҗәгатьләренең барлык очраклары турында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хәбәр итү бурычларын гамәлгә ашыруны тәэмин итә;

2.23. Муниципаль хезмәткәрләрне хокукый агартуны оештыра;

2.24. Билгеләнгән тәртиптә хезмәт тикшерүләре үткәрә;

2.25. Арча район Советы, Башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары нигезендә тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне (коррупцион хокук бозуларны профилактикалауга кагылышлы өлешендә) тикшерүне оештыра, Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләрнең үтәлешен тикшерә; Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче гражданнарның муниципаль хезмәттән киткәннән соң хезмәт шартнамәсе төзегәндә чикләүләрнең үтәлешен тикшерә;

2.26. Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренә муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча консультация ярдәме күрсәтә;

2.27. Законнарны һәм башка хокукый норматив актларны үтәү максатыннан хезмәткәрләрнең шәхси мәгълүматларын эшкәртү таләпләрен үтәүне тәэмин итә, хезмәткәрләргә эшкә урнашуда, белем алуда һәм хезмәттә зуррак вазыйфага күчүдә ярдәм итә, хезмәткәрләрнең шәхси куркынычсызлыгын тәэмин итә, башкарыла торган эшнең санын һәм сыйфатын тикшерә һәм мөлкәтнең сакланышын тәэмин итә;

2.28. Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә хезмәткәрнең шәхси мәгълүматларын саклауны тәэмин итә;

2.29 «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда каралган һәм аның нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актлар таләпләрен үтәүне тәэмин итә;

2.30. Кадрлар эшенең хезмәт законнарында һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексында билгеләнә торган башка мәсьәләләрен хәл итә.

## 3. Секторның функцияләре

Секторның төп функцияләре түбәндәгеләр:

3.1. Кадрлар эшен алып бару буенча:

1) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен кадрлар составы булдыру;

2) муниципаль хезмәт турында законнар нигезләмәләрен гамәлгә ашыру турында тәкъдимнәр әзерләү һәм әлеге тәкъдимнәрне Арча муниципаль районы башлыгы каравына кертү;

3) муниципаль хезмәткә керүгә, аны узуга, хезмәт шартнамәсе (контракты) төзүгә, муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп куюга, муниципаль хезмәттә биләгән вазыйфасыннан азат итүгә, муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәттән китүенә һәм аның пенсиягә чыгуына бәйле муниципаль хокукый актлар проектларын әзерләүне оештыру һәм тиешле документлар рәсмиләштерү;

4) муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрын һәм муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару;

5) кадрлар резервы белән эшләүне һәм аннан нәтиҗәле файдалануны оештыру;

6) муниципаль хезмәткә кергәндә граждан тарафыннан тапшырыла торган шәхси белешмәләрнең һәм башка белешмәләрнең дөреслеген тикшерүне оештыру;

7) муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча муниципаль хезмәткәрләргә консультация бирү;

8) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлары составының бердәм мәгълүмат системасына кадрлар составы турында мәгълүмат кертү;

9) үз компетенциясе чикләрендә конфиденциаль мәгълүматны яклау буенча Башкарма комитетта эш оештыруны регламентлый торган оештыру-күрсәтмә документларны килештерүдә (эшләүдә, төзәтмәләр кертүдә) катнашу: конфиденциаль характердагы белешмәләр - шәхси белешмәләр; хезмәт серен

тәшкил итүче белешмәләр; язышу серен һәм телефон аша сөйләшүләр яисә башка хәбәрләр серен тәшкил итүче белешмәләр; керү мөмкинлеге Россия Федерациясе Граждан кодексы һәм федераль законнар нигезендә чикләнгән белешмәләр (шул исәптән боерыкларр, инструкцияләр, нигезләмәләр, журналларның конфиденциальлекне яклау эшләрен оештыру һәм уздыру тәртибен билгели торган төрләре);

10) үз компетенциясе чикләрендә федераль башкарма хакимият органнарының, Татарстан Республикасы башкарма органнарының норматив хокукый актларында, Россия Федерациясенең норматив актларында, шулай ук башкарма комитетның локаль хокукый актларында билгеләнгән шәхси мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләрен үтәүне тикшереп тору;

11) аларны эшкәрткәндә (бирелгән вәкаләтләр чикләрендә) Арча район Советы, Башкарма комитеты хезмәткәрләренең (вакантлы вазыйфаларга карала торган кандидатлар) персональ белешмәләрен иминлеген тәэмин итү;

12) үз компетенциясе чикләрендә шәхси белешмәләрнең сакланышын һәм аларга рөхсәтсез кермәү (бирелгән вәкаләтләр чикләрендә) шартларын үтәүне тикшереп тору;

13) хезмәткәрләрнең хәрби исәбен алып бару;

14) кадрлар эшенең муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының һәм хезмәт законнарында билгеләнә торган башка мәсьәләләрен хәл итү.

3.2. Арча район Советында һәм Арча муниципаль районы Башкарма комитетында коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча:

1) муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законда, башка федераль законнарда, шулай ук Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында билгеләнгән вазыйфаларны үтәүне, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу турындагы таләпләрне (алга таба - хезмәт тәртибенә таләпләр) үтәүне тәэмин итү;

2) муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау һәм бетерү буенча чаралар күрү;

3) Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазыйфа биләүче затларның хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итүдә катнашу;

4) Россия Федерациясе Президентының 2002 елның 12 августындагы 885 номерлы Указы белән расланган хезмәт тәртибенә таләпләрне һәм хезмәт тәртибенең гомуми принципларын практикада куллануга бәйле мәсьәләләр буенча, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең коррупциячел хокук бозулар кылу фактлары турында яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә), Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына, башка дәүләт органнарына хәбәр итү, алар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшырмау яки дөрес булмаган белешмәләр тапшыру буенча муниципаль хезмәткәрләргә консультатив ярдәм күрсәтү;

5) үз компетенциясе чикләрендә нинди дә булса затларның аларны коррупциячел хокук бозулар кылуга этәрү максатларында яллаучы (эш бирүче)

вәкиленә, Россия Федерациясе прокуратурасы органнарына мөрәҗәгать итүләренең барлык очраклары турында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хәбәр итү бурычын гамәлгә ашыруны тәэмин итүдә катнашу;

6) муниципаль хезмәткәрләрне хокукый агартуны оештыру;

7) хезмәт тикшерүләре үткәрү;

8) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрнең, шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан бирелә торган белешмәләрнең (коррупциячел хокук бозуларны профилактикалауга кагылышлы өлешендә) дөреслеген һәм тулылыгын тикшерүне, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт тәртибенә таләпләрнең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыру;

9) үз компетенциясе нигезендә коррупциягә каршы көрәш турында норматив хокукый актлар проектларын әзерләү;

10) билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек итү;

11) муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелә торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү турында, алар өчен билгеләнгән тыюларны, чикләүләрне һәм йөкләмәләрне үтәмәүне булдырмау яисә җайга салу турында, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән гражданнар тарафыннан муниципаль хезмәттән киткәннән соң хезмәт шартнамәсе һәм (яисә) граждан-хокук шартнамәсе төзегәндә алар тарафыннан федераль законнарда билгеләнгән тыюларны үтәү турында белешмәләрне анализлау, шулай ук мондый белешмәләрне анализлаганда әлеге гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр белән алар ризалыгы белән әңгәмә үткәрү, алар ризалыгы белән алардан аңлатмалар ала, Россия Федерациясе Прокуратурасы органнарыннан, башка федераль дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарының территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән һәм оешмалардан муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү турында мәгълүмат алу (дәүләт, банк, салым яки закон тарафыннан саклана торган башка серләрне тәшкил итүче мәгълүматлардан тыш), гражданнар яки муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелгән мәгълүматларны, алынган башка мәгълүматны өйрәнү;

12) федераль законнарда каралган очракларда, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләгән гражданнарның муниципаль хезмәттән азат ителгәннән соң хезмәт шартнамәсе һәм (яисә) граждан-хокукый шартнамә төзегәндә чикләүләрне үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру;

13) ышаныч югалтуга бәйле рәвештә эштән чыгарылган затларны реестрга кертү өчен вәкаләтле дәүләт органына белешмәләр җибәрү.

**4. Сектор эшчәнлеген тәэмин итү һәм аңа җитәкчелек итү**

Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Сектор түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1. Арча район Советының, Башкарма комитетының структур бүлекчәләре һәм Арча муниципаль районының башка җирле үзидарә органнары җитәкчеләреннән билгеләнгән тәртиптә кирәкле документлар, белешмәләр, хисаплар һәм башка белешмәләрне соратып алырга.

4.2. Кадрлар мәсьәләләре буенча Арча район Советының, Башкарма комитетының структур бүлекчәләре һәм җирле үзидарәнең башка органнары, районның тиешле хезмәтләре җитәкчеләреннән билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат соратып алырга.

4.3. Сектор функцияләре буенча Арча муниципаль районы башлыгы һәм Башкарма комитет җитәкчесе карарлары һәм күрсәтмәләре проектларын кертергә.

4.4. Контрольдә тотыла торган документлар буенча мәгълүмат бирү срокларын билгеләргә.

4.5. Гамәлдәге таләпләрне һәм регламентны бозып әзерләнгән документларны кабул итмәскә.

4.6. Сектор эшчәнлеге белән законнар һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән чикләрдә сектор мөдире җитәкчелек итә.

4.7. Сектор мөдире сектор эшчәнлеген оештыру һәм тәэмин итү буенча түбәндәге функцияләр башкара:

- төзелгән максатлары буенча Сектор эшчәнлеген тәэмин итә;
-хакимият органнарында, оешмаларда, учреждениеләрдә, предприятиеләрдә Сектор исеменнән эш итә;
- Секторның эшен оештыра, хезмәт бурычларын үтәгәндә үзенә буйсынган хезмәткәрләрнең җаваплылык дәрәҗәсен билгели;
- Сектор хезмәткәрләре арасында йөкләмәләрне бүлә, аларның үтәлешен тикшереп тора;
- хезмәт дисциплинасын, эчке хезмәт тәртибен, документларның, мөлкәтнең сакланышын тәэмин итә;
- Сектор компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча документларны билгеләнгән тәртиптә Арча муниципаль районы башлыгы һәм район башкарма комитеты җитәкчесе каравына кертә;
- Секторга кергән корреспонденцияне карый, аның билгеләнгән вакытта үтәлешен тәэмин итә;
- әлеге Нигезләмәдән килеп чыга торган һәм гамәлдәге законнарга каршы килмәгән башка функцияләрне үти.

## 5. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү тәртибе

5.1. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү Арча муниципаль районы Советы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.